Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN
УНИВЕРСИТЕТ

№25 (38)

20 сентябрь 2012 ел

## • Универ хәлләре

14 сентябрь көнне **ИЛШАТ ГАФУРОВ ҖИТӘКЧЕЛЕГЕНДӘ РЕКТОРАТНЫҢ ЧИРАТТАГЫ УТЫРЫШЫ УЗДЫ**. Гадәттәгечә, икътисади һәм стратегик үсеш буенча проректор Марат Сафиуллин КФУдагы Үсеш программасының барышы белән таныштырды, университетның структур бүлекчәләре рейтингы турында мәгълүмат бирде. КФУның Яр Чаллы филиалы директоры Анатолий Макаров чыгышында кайбер кафедра исемнәрен алыштыру турындагы мәсьәләне күтәрде. Ректорат утырышы тантаналы рәвештә тәмамланды. «Ак Барс банк» ААҖның «ачык университет» проекты кысасында өстәмә һөнәри белем алучыларга дипломнар тапшырылды.

• • • •

**14 СЕНТЯБРЬДӘ КФУ**ның **ФИЗИКА ИНСТИТУТЫ БИНАСЫНДА** тантаналы рәвештә бердәм **ТУКЛАНУ КОМБИНАТЫ АЧЫЛДЫ**. Тулаем заманча, зәвык белән ремонт ясалган ашханәдә WI-FI зонасы да булдырылган. Интерьерның үзгәрүе бәяләргә берничек тә йогынты ясамаган. Комбинатта элеккечә 70-120 сумга тамак ялгап алырга мөмкин. Социаль туклану талоннары да биредә кабул ителәчәк.

• • • •

**17 СЕНТЯБРЬ КӨННЕ** университетыбызда «Когерент оптика һәм оптик спектроскопия» **УНАЛТЫНЧЫ БӨТЕНРОССИЯ ЯШЬЛӘР ФӘННИ МӘКТӘБЕ ЭШЧӘНЛЕГЕН БАШЛАП ҖИБӘРДЕ**. Өч көн дәвамында катнашучылар өчен лекцияләр, стендлы сессияләр һәм «Квант һәм когерент оптика проблемалары», «Нанооптика», «Оптик спектроскопия» секция утырышлары оештырылды.

• • • •

**17 СЕНТЯБРЬДӘ** Казан федераль университетында **ХЕМО- ҺӘМ БИОИНФОРМАТИКАГА БАГЫШЛАНГАН ФРАНЦИЯ-РОССИЯ СЕМИНАРЫ УЗДЫ**. Чараны оештыруда КФУ белән беррәттән бу өлкәдә алдынгы урында торган Страсбург университеты да катнашты. Төрле илләрдән килгән галимнәрнең бергә җыелу максаты – хемо- һәм биоинформатика өлкәсендәге яңа фәнни уңышларны презентацияләү, әлеге дисциплинаны укыту тәҗрибәсен уртаклашу.

• • • •

**18 СЕНТЯБРЬ КӨННЕ** «УНИКС» концертлар залында беренче курс студентлары, шулай ук, университетның иҗади тормышы белән якынрак танышырга теләүчеләр өчен **«СТУДЕНТ ТОРМЫШЫ БУЕНЧА ЭКСКУРСИЯ» ДИП ИСЕМЛӘНГӘН КОНЦЕРТ ПРОГРАММАСЫ ОЕШТЫРЫЛДЫ**. Югары курс студентлары үзләренең иң яхшы номерларын тәкъдим иттеләр.

• • • •

**18 СЕНТЯБРЬ КӨННЕ** КФУның Педагогика һәм психология институтындагы 51нче лекция залында цивилизацияне чагыштырмача өйрәнү халыкара җәмгыяте (ISCSC - Россия, Европа) программаларының вәкиле һәм координаторы, ISCSC Директорлар киңәшмәсе әгъзасы, Перспектив программалар һәм конференцияләр комитеты рәисе (ISCSC), Тойнби-Талбутт премиясе (2011) лауреаты, ISCSC җәмгыятенә зур өлеш керткән өчен премия лауреаты (2012), Халыкара Җәмгыять Үсеше Университеты проректоры **ВЛАДИМИР АЛАЛЫКИН-ИЗВЕКОВ БЕЛӘН ОЧРАШУ ҮТКӘРЕЛДЕ**. (Тулырак univer-smotri.ru каналыннан карый аласыз.)

• • • •

Казан университетының **ТАРИХ МУЗЕЕНДА** 1812 елгы Ватан сугышына багышланган **«УНИКЕНЧЕ ЕЛ АФӘТЕ» ИСЕМЛЕ КҮРГӘЗМӘ АЧЫЛДЫ**. Музей барлык студентларны һәм КФУ хезмәткәрләрен чакырып, көтеп кала.

• • • •

Иртәгә сәгать унда КФУның Бутлеров исемендәге аудиториясендә **«СПЕКТРАЛЬ СИСТЕМАЛАР» КОМПАНИЯСЕ TECAN, NIKON АЛДЫНГЫ АНАЛИТИК ҖИҺАЗЛАР ҖИТЕШТЕРҮЧЕЛӘР БЕЛӘН БЕРЛЕКТӘ** «Заманча аналитик методлар, җиһазларның фәндә һәм гамәлдә кулланылышы» исемле **ФӘННИ-ГАМӘЛИ СЕМИНАР УЗДЫРАЧАК**.

*kpfu.ru сайты материаллары файдаланылды.*



Әмир Фазлыәхмәтов фотосы

# Казан үзәгендә мөгезборыннар «яши»

**Динара ӘХМӘТОВА,**
хәбәрче

Кичә, ягъни 19 сентябрь көнне, университетыбызның Геология музеена бозлык дәверендәге фауна коллекциясе тапшырылды.

Мондый коллекцияне кайдан тапканнар дип баш ватасызмы? Әлеге коллекциягә Казанда, нәкъ шулай башкалабызның үзәгендә урнашкан Татар матбугаты йортында тап булалар. Белүебезчә, бу бина 2013 елда үз эшчәнлеген кунакханә буларак башлап җибәрәчәк.

Тарихи истәлекләрне безнең уку йортын тәмамлаган, КФУның Кайгыртучанлык шурасы әгъзасы, «Рубин» футбол клубы президенты Валерий Сорокин тапшырды. Аның сүзләренчә, экспонатлар яхшылап дүрт тартмага тутырылган. «Эшчеләр чүп-чар дип ташламаган, шунда ук миңа хәбәр иттеләр. Килеп күргәч, белгечләргә мөрәҗәгать иттем. Ниндидер зур ачышлар ясап булыр дип уйламыйм, ләкин музей өчен бик уникаль мирас», – дип фикерләре белән уртаклашты Валерий Сорокин.

Коллекция составында мамонт, бизон һәм мөгезборыннарның баш сөякләре, скелет өлешләре, тешләре бар. Коллекцияне тапшыручыга аеруча йонлы мөгезборын калдыклары бик кызыклы булып тоелган. Әлеге төр хайваннар бозлык чорында яшәгән. Археологик эзләнүләр күрсәткәнчә, аларның озынлыгы 3,5 метрга, ике мөгезнең берсе хәтта бер метрга кадәр җиткән. Россиядә бу төр мөгезборыннарга бәйле коллекциянең иң зурысы да нәкъ менә КФУның Геологик музеенда саклана. Хәзер ул тагын да тулыланды.

Бүләк ителгән экспонатларны белгечләр Идел елгасы буенда, Тәтеш районы тирәсендә табылган дип саный. Мондый төр ачышлар музей эшчәнлегендә беренче түгел, ләкин әһәмияте аеруча зур. Ул мамонтның 100 теше булу белән үзенчәлекле. Чарада катнашкан фәнни эшчәнлек буенча проректор Данис Нургалиев: «Коллекциянең күпчелеген тешләр генә тәшкил итүе аеруча игътибарны җәлеп итә. Күрәсең, кемдер нәкъ менә тешләрне генә җыйган», – диде. Кызганыч, коллекциянең кемгә караганын, аның хуҗасын белүе авыр. Ул йортта, мөгаен, йә геолог-палеонтолог, йә берәр коллекционер яшәгән.

«Әлеге коллекция өчен нидер өмет итәсезме?» – дигән сорауга Валерий Сорокин бик төгәл итеп кенә: «Үз уку йортыма булыша алуым белән бәхетлемен. Без әле башка биналарны реставрацияләү эшен дә алып барабыз. Тапсак, рәхәтләнеп бүләк итәчәкмен», – диде.

Бозлык чорының фауна үрнәкләре белән Кремль урамы, 4нче йорт буенча урнашкан КФУның Геология музеенда танышырга мөмкин. Айның һәр өченче якшәмбесендә керү иреклe.

## • Бездә кунак бар

# Алдынгы бизнес галимнәре - КФУда

**Рәдифә ШАФИКОВА,**
хәбәрче

18 сентябрь көнне Казан федераль университетына Пенсильвания штатыннан (АКШ) бер төркем iCarnegie Питтсбург делегациясе килде.



Диана Поварова фотосы

1998 елда Карнеги-Меллон университетында iCarnegie үз эшен башлап җибәрә. Дөрес, ул бер бүлек сыйфатында гына эшли, шуңа да карамастан берничә ел эчендә егерме илдән килгән ике йөз меңнән артык студенттан тәҗрибәле белгеч ясап чыгарган мәктәп бу! Тагын шунысы кызык: мәктәптә укып чыгучылар барлыгы ике йөзләп компания төзеп, төрле илләрдә ун меңнән артык эш урыны булдырган!

**Ахыры 2нче биттә.**

• Сәясәт

# Игътибар! Президент сөйли!

Динара ӘХМӘТОВА,
хәбәрчепәр



*Уку йортларының матди-техник базасын ныгыту, заманча мәгариф технологияләре булдыру буенча да зур эш башкарыла. Укытучылар әзерләү мәсьәләсенә аеруча җитди карарга кирәк. Мәктәпләргә яңа буын укытучы-лидерларны җәлеп итү, бу профессиянең абруен күтәрү зарур.*

Соңгы арада конкурентлыкка сәләтле яшьләрне тәрбияләргә кирәк дигән сүзләрне еш ишетәбез. Ил башлыгы бу мәсьәләнең чишелешен укыту системасын яңа баскычка күтәрү һәм сәламәт яшәү рәвешенә зур игътибар бирүдә күрә. Болар нәтиҗәсендә яңа икътисади үсешкә ирешеп булачак.

Президентыбыз Рөстәм Миңнехановның Татарстан Республикасы Дәүләт Советына мөрәҗәгатендә яшьләргә шундый игътибар бирелә. Әлбәттә ул икътисади, сәяси мәсьәләләрне, мәгариф һәм фән, сәламәтлек, иҗтимагый өлкәгә кагылышлы проблемаларның барсын да күтәрде, уңышлар белән таныштырды. Милләтебез киләчәге дә читтә калмады...

Мәгълүмати өлкәдә зур үзгәрешләр. без ияләшкән массакүләм мәгълүмат чаралары урынына электрон ресусрлар, социаль челтәрләр килүе беркемгә дә сер түгел. Яшь буын газета-журналларның ни икәнен оныта бара кебек. Әлбәттә, кәгазь вариантын! Телевидениегә әле күпмедер ихтыяҗ яши, ләкин интернет аның мөмкинлекләрен дә чикли башлады кебек. Без хәзер мәгълүматның ким дигәндә 70 процентын интернеттан алабыз. Ил башлыгы фикеренчә, барыбызга да яңа шартларда эшләргә өйрәнәсе бар.

Яшьләрнең җәмгыятьтәге социаль урыны турында да онытмаска кирәк. Моның өчен яшь буын белән алдан ук эшли башларга кирәклеген билгеләп үтте. Балалар һәм яшьләр өчен төрле интеллектуаль-иҗади проектлар бар, аларга дөрес юнәлеш бирү мөһим.

2012 ел тарихи-мәдәни мирасны саклау елы буларак үтә. Яңа елга аяк басканчы, үткәнгә нәтиҗә ясау, кайбер уңышларны билгеләп үтү кирәк. Рөстәм Миңнеханов бу теманы да игътибардан читтә калдырмады. Ел дәвамында һәйкәлләрне, рухи мәдәниятне саклау буенча зур эшләр башкарылды. Яңа музей комплекслары, тергезелгән корылмалар яшь буын өчен тагын бер мәдәни-агарту һәм белем бирү үзәге булып тора. «Тарихи мирасыбызга карата булган мәхәббәтне, хөрмәтне ниндидер бер программа яисә акция кысаларына гына кертеп карау дөрес түгел. Бу – мәңгелек бурычыбыз», – дип басым ясады.

Без тагын традицияләргә, гореф-гадәтләргә дә игътибарыбызны арттырырга тиеш. Алай гына да түгел, җөмһүриятебездә яшәүче башка милләтләрнең мәдәниятенә дә хөрмәт белән карасак иде. Гомумән, кеше арасындагы мөнәсәбәтләрне җайлау, милләтара диалог кора белү, сәяси мәдәният кебек җитди проблемаларны да читтә калдырырга ярамый. Президентыбыз әлеге мәсьәләрне күтәреп, ике дәүләт теле булган татар һәм рус телен мәҗбүри өйрәнергә кирәклеге турында әйтте. Бу республикабызда яшәүче төрле милләтләр арасындагы мөнәсәбәтне тагын да ныгытачак. Чит төбәкләрдә яшәүче милләттәшләребез белән мөнәсәбәт көннән-көн яхшыра. «Бу елның июнь аенда татар дөньясына ТНВ Планета каналын карау мөмкинлеге туды. Киләсе елның беренче гыйнварыннан, татар телен өйрәнергә теләгән һәр кеше өчен «Ана теле» онлайн-мәктәбе эшли башлаячак», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Президент IT-парк эшчәнлеген дә читтә калдырмады. Әлеге юнәлеш буенча уку йортыбызның да уңышлары мактанырлык. Россия күләмендә масштаблы уникаль проект – Иннополис тормышка ашырылып килә. Бирედә IT белгечләргә яшәү һәм эшләү өчен иң яхшы шартлар тудырылачак. Бу территориядә шулай ук IT-университет ачылачак.

Уку йортларының материаль-техник базасын ныгыту, заманча мәгариф технологияләре булдыру буенча да зур эш башкарыла. Укытучылар әзерләү мәсьәләсенә аеруча җитди карарга кирәк, анынча. Мәктәпләргә яңа буын укытучы-лидерларны җәлеп итү

һәм профессиянең абруен үстерү зарур. Мәктәп балаларны тәрбияләү, иҗади сәләтләрен үстерү үзәге булып тора. «Дәрестән соң мәктәп» проекты укучылар өчен тагын бер яхшы мөмкинлек. Мәктәпләр төрле түгәрәк һәм спорт секцияләре өчен иртәдән алып кичкә кадәр ачык булырга тиеш.

Яхшы тәрбия белән бергә сәламәт яшәү рәвеше турында да онытырга ярамый. 2013 елда узачак Универсиада – безнең өчен яхшы стимул. Ул нибары ике атна булачак, ә аннан калган мирас безгә ничә сәламәт тә, спортны яратучы да булган яшь буынны тәрбияләргә ярдәм итәр.

«Заман бик тиз үзгәрә. Уңышка ирешер өчен, без вакыт белән бергә атларга тиеш. Киләчәк – бүген аңа әзерләнүчеләр кулында!» – дип чыгышын тәгәлләде Президентыбыз Рөстәм Миңнеханов. Югарыда санап үтелгән теләктәкъдимнәр кәгазьдә яки сүздә генә калмас дип ышанасы килә. Президент әйткәнгә генә нидер эшләү, гомумән, дөрес гамәл түгел. Яшь буынны үзе аңлап, үзе белеп эшләрдәй итеп тәрбияләргә кирәк.

• Белем баскычлары



# Цитаталанасың килсә - инглизчә бел!

Алинә САДЫЙКОВА,
хәбәрче

**Фәнни-гыйльми эшчәнлек белән шөгыльләнүчеләр өчен бер яхшы яңалык бар: Казан Федераль университетында THOMSON REUTERS компаниясе «Галимнәр бренды: синең цитатаң кулланылышка керсен өчен нишләргә?» исемле семинар уздырды.**

Чарада катнашкан кешеләр үзләре өчен файдалы мәгълүмат, киңәшләр тыңлады. Семинар 18 сентябрь көнне Лобачевский исемендәге фәнни китапханә бинасында уздырылды. Чараны химия фәннәре кандидаты, «Thomson Reuters»ның клиентларны өйрәтү һәм аларга ярдәм итү буенча белгеч – Сергей Парамонов алып барды.

Белгеч чыгышын килгән кунакларга рәхмәтен белдерү белән башлап җибәрде. Соңрак ул цитаталауның бүгенге көндә никадәр әһәмиятле икәнлеген, аңа басым ясарга кирәклеген аңлатып үтте: «Цитатаң кулланылышка кереп китсен өчен иң мөһим фактор – башкаларның синең эшең белән таныш булуы. Галимнең исеме, аның эшчәнлеге белән ассоциацияләнергә тиеш һәм киресенчә. Икенче төрле әйткәндә, «исем», ягъни бренд ясый белергә кирәк. Бу исем ясауның иң җиңел вә иң кулай варианты – конференцияләрдә катнашу һәм журналларда басылу. Журналның дәрәҗәле булуы да мөһим».

Семинар ике сәгать тирәсе дәвам итте. Сергей Парамонов басмаларны әзерләү стратегиясе мәсьәләсендә киңәшләр бирде. Чара барышында, шулай ук, «Web of knowledge» цитата кулланылышының индексын билгеләү һәм фәнни мәкаләләр эзләтү сервисы, «Web of Science» мәгълүмат базасы, «Journal Citation Reports» дип аталган басмаларны бәяләү өчен аналитик журнал, «EndNote Web» библиографияләр белән эшләү программасы һәм «ResearcherlD» фәнни эзләнүченең визит карточкасы турында ресурслар турында мәгълүмат бирелде. Алар белән ничек эшләргә кирәклеген аңлатты галим.

Семинарда, актуаль мәсьәләләр күтәрелде, чөнки бүгенге көндә цитаталану – ул галимнең генә түгел, ә, гомумән, уку йортының да дәрәҗәсен билгели торган күрсәткеч.

Thomson Reuters ресурсларына мәкаләләр, гадәттә, инглиз телендә басыла. Шулай булгач, иптәшләр, безгә инглиз телен яхшырак өйрәнергә тагын бер стимул булды. Стимул дигәндә дөньякүләм цитаталану, үзеңнең һәм уку йортыңның, илеңнең абруе үсү дә күзаллана.

• Бездә кунак бар

# Алдынгы бизнес галимнәре - КФУда

**Башы 1нче биттә.**

1998 елда Карнеги-Меллон университетында iCarnegie үз эшен башлап җибәрә. Дөрес, ул бер бүлек сыйфатында гына эшли, шуңа да карамастан берничә ел эчендә егерме илдән килгән ике йөз меңнән артык студенттан тәҗрибәле белгеч ясап чыгарган мәктәп бу! Тагын шунысы кызык: бу мәктәптә укып чыгучылар барлыгы ике йөзләп компания уйлап табып, төрле илләрдә ун меңнән артык эш урыны булдырган!

Университет кунаклары арасында iCarnegie компаниясенең директоры Гил Таран, вице-президент (Global Business Development) Рон Шелл, вице-президент Эндрю М. Амальфитано һәм мәгълүмат үзәге җитәкчесе Майкл Бриджит бар иде. Алар университет җитәкчелеге һәм институт директорлары белән очраштылар.

Үзенчәлекле очрашуны КФУның фәнни эшчәнлек буенча проректоры Данис Нургалиев ачып җибәрде. Чит ил кунакларын ул университеттагы математика фәненең торышы, заманча технологияләрнең укытучылар һәм студентлар тарафыннан ни дәрәҗәдә кулланылуы белән таныштырды.

Мөхтәрәм кунак Гил Таран чыгышында: «Безнең Казан университетына бер төркем булып килеп төшүебез юкка гына түгел. Беренчедән, КФУ эшчәнлеге белән танышырга теләдек. Шул ук



Диана Поварова фотосы

вакытта мәгълүмати технологияләрнең үсеш дәрәҗәсе кызыксындыра. Икенчедән, үзебезнең университет белән хезмәттәшлек итү мөмкинлекләрен карарга булдык», – диде.

IT-белгечләргә бәйле фикер алышу аеруча җанлы булды. Очрашуда катнашучылар аларны әзерләү, IT технологияләрнең Казан университетында һәм Карнеги-Меллонда кулланылышы турында сөйләште. Мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүмати системаларның Югары мәктәбе директоры Айрат Хасьянов, Хисаплау математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институты директоры Рөстәм Латыйпов үзләре җитәкләгән бүлек эшчәнлеге белән презентация ярдәмендә таныштырды.

Бу уңайдан iCarnegie компаниясе директоры: «КФУның мәгълүмати технологияләр буенча үсеш юнәлеше бик кызыклы. Ул университетка тагын да югары баскычларга күтәрелергә ярдәм итәр, чөнки әлеге өлкә буенча халыкара хезмәттәшлек итү мөмкинлекләре зур», – дип фикерләрен уртаклашты.

Америкалылар белән хезмәттәшлек итү КФУ өчен дә бик файдалы. Рөстәм Латыйпов әйтүенчә, Карнеги-Меллон мәгълүмати технологияләр, программалаштыру өлкәсендә дөньяда беренче-икенче урында тора. Андый тәҗрибә безгә дә зыян итмәс.

Рәсми өлештән соң, океан артындагы кунакларны Физика институты, Геология һәм кара алтын-газ технологияләре институтының фәнни-тикшерену лабораторияләре белән таныштырдылар. IT-лицей, Н.И.Лобачевский исемендәге һәм 131нче физика-математика лицейларын да күзәтә алды океан артыннан килгән мосафирлар.

*(Бу турыда **univer-smotri.ru** сайтыннан карый аласыз)*

● Безнең юбиляр

## Рифә РАХМАН: «Мин усал түгелдер инде»

**Рифат СӘЛАХ**

БЕРЬЮЛЫ ШАГЫЙРӘ ДӘ, ЯЗУЧЫ ДА, ГАЛИМӘ ДӘ, ТӘНКЫЙТЬЧЕ ДӘ БУЛУ МӨМКИНМЕ? ӘЛБӘТТӘ. УНИВЕРСИТЕТЫБЫЗДА ДА АНДЫЙ ШӘХЕС БАР. УЛ ӘЛЕ ӨЧЕНЧЕКӘН ГЕНӘ БЕРЕНЧЕ ЮБИЛЕЕН БИЛГЕЛӘП ҮТКӘН ТАТАР ФИЛОЛОГИЯСЕ ДОЦЕНТЫ РИФӘ РАХМАН. ҺАМАН СТУДЕНТЛАР БЕЛӘН БЕР ДӨНЬЯДА ЯШИ. АЛАР КӨЛСӘ КӨЛӘ, АЛАР ЕЛАСА ЕЛЫЙ. АНЫҢ КҮЗЛӘРЕНДӘ ЯШЬЛЕК ҮЗЕ БАЛКЫЙ!



**– Рифә апа, студентларыгыз сезне усал, таләпчән диләр. Ә чынлыкта сез нинди?**

– Мин укытучы буларак усал түгел, ә таләпчән дигәне белән килешәм. Бераз усал булып күренергә тырышам гына. Юбилей кичәмдә элекке студентым Рөстәм Галибәк тә: «Рифә апаны бөтен кеше дә усал дип әйтә, әмма аның нинди йомшак, нинди нечкә күңелле кеше икәнлеген белмиләр», – диде. Усал дигән сүз йөз егерме кешелек аудиторияләрдә укыткан чакта китте. Аларны тотып торырга кирәк. Бервакыт бер студент: «Рифә апа, без сезнең усал икәнегезне укырга кергәнче үк белә идек, чөнки бөтен студентлар шулай ди». Алар усал икәнлегемне: «Дәрес башлангач, кертми», – дип бәяли. Бу усаллыкка керми торгандыр инде, күбрәк таләпчәнлек. «Ә сезне башка укытучылар кертәмени?» – дип сорагач: «Сездән кала барысы да кертә», – диләр. Димәк, алар тәрбияләмәгән әйберне, егерме-утыз кешенең усаллыгын бергә җыеп тәрбияләргә тиеш булам. Укытучы кеше ничек итеп дәрес вакытында студентны кертеп-чыгарып йөрергә тиеш! Кайбер кешегә формаль күренгән шундый таләпләрем бар. Өйдә дә чик дәрәҗәдә йомшак, дәрестә дә елап җибәргәлим. Берәр кешенең авырганын күрсәм, берәр студентка дөрес булмаган сүз әйткәнемне аңласам, хәтта дөрес сүз әйтеп, теге студент оялса – күземнән яшь тәгәрәп төшә минем. Таләпләрне, йомшак булуыма карамастан, киявемә дә, кызыма да куям. Алар аңлый, авыр кабул итми.

**– Тормышта сезнең өчен иң мөһиме нәрсә?**

– Намуслы яшәү. Балаңа карата намуслы булу. Аны син орыша аласыңмы, тәрбия бирәсеңме, төрле эшләргә өйрәтәсеңме? Иманың кушкан әйбергә өйрәтергә кирәк аны, заман кушканга түгел. Язучыларны да, студентларымны да дәрәҗәле кеше булганга мактамыйм. Язган чакта да заманча булсын дип тырышмыйм. Бүгенге идеологияне дә яклап бетермим. Коммунистларны да бетереп атмыйм. Һәрберсенең уңай, тискәре якларын күрәм. Иманлы яшәү – динилек кенә түгел. Үзем Аллага ышанам, әмма Аллага ышана торган кешеләр арасында имансызларны күбрәк тә күрдем бугай. Намуслы, гөнаһ эшләмичә яшәгән кешеләр барсы да Алланы танууга таба килә. Намаз укып йөргән кешеләр арасында зур гөнаһлар эшләп төрмәгә эләгүчеләрне дә беләм. Шуңа күрә, бу Аллага ышана да, иманлы, намуслы дип санамыйм әле.

**– Китапларыгызны халык яратып укый, чыгуга алып бетерәләр...**

– Иң күбе бер ай тора. Бу көнгә кадәр шулай булды. Сәбәбен иҗатым тормышчан булудан дип саныйм. Максатым: уйлап чыгармыйча язу. Нәкъ тормыштан алынган хәл көтелмәгәнлеге белән ышанмаслык була да. Киләчәктә дә шулай булыр дип әйтә алмыйм – укучы да үзгәрә! Бүген әле китап укучы бар. Чын китап укучы иҗатымны һичшиксез ярата. Киләчәк укучысы нинди булыр? Бүген тәрбияләнгән буын яратырмы – моңа гарантия биреп булмый. Шушы көннәрдә берничә кибетне йөреп чыктым. Юбилей уңаеннан дусларыма китап бирергә кирәк, әмма юк. Алып бетергәннәр.

**– Студент чагыгызның иң кызык вакыйгасын искә төшерегез әле.**

– Студент чакта һәр көн кызык. Кайбер әйберләрдән читтәрәк тә калганмындыр. Беренче курста ук кияүгә чыктым бит. Һәр вакыйга – бер хикәя. Берьюлы берничә көн йокламаган килеш дәрескә килдем. Марсель абый Бакировның дәресләре шул кадәр кызык. Төрле мисаллар белән сөйли, шулай да йокыга киткәнмен. Марсель абый лекциясен төш итеп күрәм имеш. Ул сөйләгән фольклор герое булып упкын төбенә килеп җиткәнмен. Ләис тә (*Рифә апаның ире – Р.С.*) шунда: «Үлмә, үлмә!» – диеп мине дерелдәтә. Уянып китсәм, ул Марсель абый икән. Тыным да чыкмый йокыга киткәч, үлде мәллә диеп куркып уята башлаган.

**– Язучылык, галимәлектән кала нинди хоббиларыгыз бар?**

– Яратмаган бер эшем дә юк. Элек рәсем ясый идем. Юбилей кичәмдә рәсем буенча укытучым: «Утыз ел дәвамында үрнәккә Рифәнең рәсемнәрен күрсәтәм», – диде. Ни кызганыч, үзем ясаган рәсемнәрне өйдә сакламадым. Бакча эшләрен дә бик яратам. Итек басу, бәйләү эшләрен дә бик күп эшләдем, әмма акча өчен тир түгелгән андый эшләрдән бик ардым. Бер генә белмәгән әйберем: хәзер машина төзәтә алмыйм.

**– Әсәрләрегездә Урта Азия якларында йөргәнегез сизелә.**

– Беренчедән, элек аспирантурада алар белән укыдык. Аларның тормышын яздым. Икенчедән, анда дусларым күп. Даими рәвештә кунакка да йөрдем. Язуның максаты – төрки дөньяның байлыгын, киңлеген күрсәтү, ә төп максат: без дә бер гасыр, ике гасыр элек шундый гореф-гадәтләр белән яшәгәнбез дип әйтергә телим. Үзбәкне, таҗикны язам кебек, ә чынлыкта ул бер гасыр элек яшәгән татар кешесенең тормышы.

**– Сезнеңчә, татар әдәбияты дөньяда нинди урын тота?**

– Татар әдәбияты сан ягыннан безнең халкыбызга, татар телле халык микъдарына караганда шактый зур. Әдәбиятыбызны төрки халыклар арасында чагыштырсаң, сыйфат ягыннан иң югарыларыннан: азәрбәйҗан әдәбияты, татар әдәбияты. Әмма шушы югарылыкны аңа берничә генә кеше тотарга ярдәм итеп тора. Кызганыч, иң көчле прозаикларыбыз, шагыйрьләребез дөньяда билгеле түгел. Дәрәҗәле шагыйрьләребез тәрҗемә ителә. Әдәбиятыбызны илленче елларда нык үстереп җибәргән кеше – Роберт Әхмәтҗанов. Ул – дөнья әдәбиятында иң зур шагыйрь булырлык. Әгәр шундый талантларны күздә тотсак, әдәбиятыбыз шактый югары.

● Илһам канатында

## Яңа җитәкче – яңа сезон!

**Гөлчирә ИМАНКУЛОВА,**
татар филологиясе бүлеге студенты

«ИЛҺАМ» СҮЗЕН ИШЕТҮГӘ, НИГӘДЕР БӨТЕН КЕШЕГӘ ДӘ БЕР ӘЙБЕР КҮЗ АЛДЫНА КИЛӘ. СИН ДӘ ШУЛАЙ УЙЛЫЙСЫҢМЫ? ӘЛБӘТТӘ, ТАТАР ФИЛОЛОГИЯСЕ БҮЛЕГЕНДӘ ЭШЛӘП КИЛӘ ТОРГАН «ИЛҺАМ» ТҮГӘРӘГЕ!

Иҗат итү, хыяллану, үз-үзеңне сынап карау өчен менә дигән мөмкинлек! Телисең икән шигырь, телисең икән хикәя яз, хәтта роман яки драма иҗат итәргә дә мөмкин. Ә әсәреңнең уңышлы язылган булу-булмавы хакында сөйләшү, шәхси мөмкинлекләреңне, язу стилеңне билгеләүне син инде безгә калдырып тор. Әйе, чыннан да, нинди генә күләмдәге әсәр булуына карамастан, без сиңа бәя бирәчәкбез. Без дигәннәрем, «илһамчылар», ягъни «Илһам» түгәрәгенә һәрдаим йөрүчеләр.

Һәр атна саен уза торган түгәрәк утырышында билгеле бер жанрга караган, яисә аерым бер студентның иҗат җимешләре белән танышып чыгу, яисә бирелгән нindидер бер темага алдан ук язып килгән мәкалә, хикәя, шигырьләр укыла. Түгәрәккә йөрү мөмкинлегенә берәү өчен дә чикләнми, әлбәттә. Кемнәрдер иҗат итүләрен инде мәктәп елларында ук башлап, бирегә тәҗрибәлерәк булып киләләр. Ә кемнәрдер, бәлки, үзләрендә иҗат итәсе килү теләген тоеп, нindидер әдәби әсәр тудырасы килү теләге белән янып йөриләрдер. Һичшиксез «Илһам» түгәрәге һәркайсы өчен дә мондый уйниятләрне тормышка ашыру урыны булыр, минемчә.



«Илһам» түгәрәге 13 сентябрь көнне яңа оештыручысы - Динара Әхмәтова белән танышты. Динара безнең чыгарылыш студенты, түгәрәкнең даими иҗатчысы да буларак, «Илһам» түгәрәген биш бармагы кебек белә. Шунлыктан, аның әлеге вазыйфаны башкаруы очраклы түгел, иншалла, нәтиҗәсез дә булмас. Беренче җыелышта, бер-беребез белән таныштык.

Хәзер Татар филологиясе бүлеге булганлыктан, «Илһам» түгәрәге белән беррәттән элек Казан дәүләт университетында актив эшләгән «Әллүки» әдәби-иҗат берләшмәсе дә үз эшен алып бара. Түгәрәгебезнең тәүге утырышында әлеге иҗат берләшмәсе белән дә очрашуларны еш уздырып, аралардагы җылы мөнәсәбәтләрне ныгытып торырбыз дигән фикергә килдек. Елдагыча, «Илһам» үзенә яңадан-яңа студентларны җыйды: беренче курска укырга килгәннәр дә, югарырак курсларда укып та, яңа гына иҗат итә башлаучылар да бар. Түгәрәккә даими йөрүчеләр, яңа килгәннәргә үз киңәшләрен биреп, яңа мохиткә ияләшеп китәргә ярдәм итү юллары күрсәтергә тырышса, түгәрәкне оештыручыларга теләк-тәкъдимнәрен дә җиткерде. Җыелышта Татар филологиясе бүлеге мөдиренең тәрбия һәм иҗтимагый эшләр буенча урынбасары Хөснетдинов Дамир Хәйдәр улы да бар иде. Ул безнең эшчәнлеккә булышып торырга, очрашулар оештырырга сүз бирде. Түгәрәкнең чираттагы утырышлары «Татар әдәбияты тарихы кафедрасы» укытучылары белән берлектә дә үтәчәк. Алар да безгә үз киңәшләрен бирәчәк.

Түгәрәкнең даими эшләве өчен анда йөрүчеләр, иҗат итүчеләр бар. «Илһам канатында» җыентыгының 3нче басмасына материал туплана. Димәк, хәерле сәгатьтә диясе генә кала! Иҗатка гашыйкларны үзебездә көтеп калабыз!

● Чәнечке

## Бирешмә, студент!

**Динара ЗИННӘТОВА,**
журналистика һәм социология факультеты студенты

*Студент вакыты - күңелле чак, зур өметләр чоры, гомер буена хәтердә якты хатирәләр калдыра торган вакыт. Шулай да күпләр өчен югары уку йортында белем алуга шактый кыенлыклар, проблемалар юлдаш була. Аларның күбесе безнең замана шартларында, әлбәттә, акча мәсьәләсенә килеп терәлә. Нинди алар? Чишү юллары бармы?*

*Башка шәһәрдән килгән студентны, беренче чиратта, яшәү урынын табу мәсьәләсе кызыксындыра. Булачак универсиада бу проблеманы беркадәр чишеп диярга мөмкин. Өр-яңа,шактый уңайлы шартлар тудырылган тулай тораклар - Универсиада авылы университет студентларына үз ишекләрен ачып җибәрде. Анда күчкән студентлар, аларның ата-аналары сөенеп туймады. Кайбер кешеләр арасында бу биналарга сокланып, «ниһаять, студентлар турында да кайгырталар», – дигән фикер таралды. Шулай да элеккеге тулай тораклар әле дә бар. Аларда яшәүче студентлар саны да аз булмаганын онытырга кирәк түгел. Быел барлык 4-5 курс студентларын иске тулай торакларга күчерделәр. Универсиада авылыннан күчкәч, мондагы җитешсезлекләр тагын да ачыграк сизелә: тугыз катлы бинага бер генә душ булу, лифт эшләмәү, бүлмәләрдәге һава салкын, суыткычлар юк. Җиденче каттан беренче катка душка төшеп, «телне асылындырып» кире менеп җиткәндә,үзеңне инде яңадан пычранган, һәм, җитмәсә, беренче каттагы җилдән салкын тидергән итеп хис итәсең. Бер карасаң, моннан бердәнбер чыгу юлы – арендага фатир эзләү. Әмма бүгенге студентка фатир табу да шактый кыен: кая карама – риелторлар,агентлыклар чорнап ала.*

*Университет студентларының күпчелеге фаст-фудка ияләшә – төп бинада да, икенче корпуста да «слойка», тозлы сохари, газлы су популярлык казанды. Студентларның күп булуын чамалап, кафе-буфетларда бәяләрне арттырып куялар. Кыска тәнәфесләрдә ашханәгә кадәр баруы да кыен – зур чиратта да торасы килми, парга соңга калырга да теләк юк. Шулай итеп күнегә студент коры-сарыга.*

*Журфакта белем алучылар Товарищеская урамындагы бинага өйрәнеп җитте бугай. Шулай да биредәге буфет, биредәге ризыкларның сыйфаты да, төрләре дә күпләрнең кәефен төшерә. Моннан чыгу юлы бер: тиз генә тамак ялгап алырга ризыкны үзең белән алып килү. Чипсы, сохари урынына – мюсли батончигы; газлы су урынына – эчә торган йогурт булса да, сәламәтлек өчен файдалырак булыр.*

*Мөгаен, иң җитди проблемаларның берсе - ул студент алдындагы билгесезлектер. Элек, белгәнебезчә, югары белем дә түләүсез, уку йортын тәмамлауга, буш вакансия дә сине үзе көтеп торган. Әйе, бүген – заманасы, мәнфәгатьләр, кешеләр үзләре дә башка төрле. Шулай да укыган өчен зур суммалар түләп тә,киләчәктә эш табуны ничек тә булса гарантияләү һич комачау итмәс иде.*

*Проблемаларны чишү, беренче чиратта, үз-үзеңә ныклы ышаныч кирәк. Югары уку йорты бусагасын атлаганчы, син бөтен кыенлыкларыңны әтиәни җилкәсенә тапшырып, һәрвакыт әзергә бәзер яшәгәнсеңдер. Хәзер сиңа бу гадәтеңнән арынырга туры килер. Шуңа күрә мөстәкыйльлеккә омтыл, проблемаларыңны мөмкин булган кадәр үзең хәл итәргә өйрән, дустым! Әйтик, буш вакытыңда акча эшләү өчен берәр ысул эзләргә керешсәң укып бетергәнче тәҗрибә җыярга дә өлгерерсең, киләчәккә планнар корырга нигезең дә булачак. Бу эш синең укыган белгечлегеңә якын булсын. Иң мөһиме - үзеңнең булдыклы икәнлегеңә, үз көчеңә ныклап ышану. Уңышлар телим!*

Әдәби Ат

# Җир белән күк арасында

**Айгөл АБДРАХМАНОВА**
татар филологиясе бүлеге студенты

*(Хикәя)*

Күп катлы йортлар... Күккә ашкан таш пулатлар... Болар барысы да табигатьтән качып, үз эчләренә бикләнүче кешеләрнең яшеренү урыннары. Дөнья куучы адәм балаларының «Акча!» - дия-дия күзләре тонган. Тышта алтын көз булды ни дә, көмеш кыш булды ни – аларга барыбер. Таш йөрәкле таш пулатлар эчендә яшиләр, кешеләрнең дә йөрәкләре ташка әйләнгәнме икән әллә?! Күңелләрендәге бозның куркыптыр инде, алар хәтта җәйнең җылы коякашыннан да качалар.

Менә бүген дә шәһәр халкы таш биналар эченә кереп югалды. Июльнең эссе көннәрен җилләткечләргә алмаштырды алар. Йөзләренә битарафлык битлеген киеп, кампитр артларына кереп утырдылар һәм ...дөньяларын онытып шунда чумдылар. Ә мин исә җәйге табигатьнең матурлыгы белән хозурланып, урамнар буйлап йөрим, сирәк кенә исеп куючы йомшак җил белән шаярам, җылы кояш нурларында иркәләнәм. Рәхәт... Кояшка тагын да якынрак буласы килә. Мин, максатыма ирешергә теләп, югарыга үрмәлим. Беренче кат, ике, өч... унөч, ундүрт, унбиш...

Менә мин унбиш катлы йортның түбәсендә. Кешеләрдән өстә. Җир белән күк арасында. Билгесезлектә. Тирә-якта чиксез зәңгәрлек, мамык болытлар һәм... һәм аска томырылырга әзерләнеп «канатларын җәйгән бер кош». Карап торышка, кызга 18-20 яшьләр тирәсе. Өстендә кыска кара күлмәк, җилкәсенә салган юка соры шарф – барысы да кайгы билгесе. Ләкин боларның берсе дә кызның якты йөзен караңгылатмый. Тәртипсез рәвештә тузгыган җирән чәчләр аратирә исеп куйган җилдә селкенешә. Җирән чәч бөдрәләре дә, җилкәсендәге шарф та тизрәк очарга теләләр бугай. Ләкин кыз ашыкмый әле.

Мин, аның сискәнүеннән куркып, аска чүгәлим дә түбәгә таба елышам... Һәм таш йөрәкле таш пулатның инрәү авазын ишетеп тынып калам.

- Синең кебек хәлдә калганнарны күп күрдем инде мин. Кайсы гаиләсеннән унмаган, кемнендер эштә мәшәкатьләр килеп чыккан. Кемдер эчкән баштан сикерә. Ә сине монда нәрсә китерде?!

Кыз берни дәшмәде. Түбә дә җавап таләп итеп азапланмады. Бары үзалдына ыңгырашкан төсле сөйләвен дәвам итте:

– Өч-дүрт көн элек минем янга бер яшь егет менгән иде. Башта бертуктаусыз тәмәке көйрәтте. Бераз тынычлангач, бөтен эч серләрен ачып салды.

Моннан берничә ел элек егет азартлы уеннар белән мавыга башлаган. Бер гөнаһсыз булып тоелган бу кызыксыну, аны әкренләп үз чоңгылына алып кереп киткән. Башта гади уен автоматлары булса, соңрак карталар алмашка килгән. Иртән - эш, кич - уен. Шулай ай арты ай, ел арты ел узган. Моңа кадәр гел җиңеп килгән уенчы, карталарга кучкәч, оттыра башлаган. Йөз сумын, меңлекне, аннан бөтен хезмәт хакын. Үз көче белән эшләп алган акча гына җитми башлагач, бурычка кергән. Тагын оттырган. Туганнарына сиздермичә генә, өйдәге әйберләрне ташый башлаган. Барысын да оттырган. Соңгы уеннарның берсендә зур кешеләр белән уйнап, зур проблемаларга тап булган. Шушы сазлыкка гомерлеккә кереп батканлыгын, әҗәтләрен беркайчан да түләп бетерә алмаячагын аңлагач, минем янга килергә булган...

Мин аны бу адымыннан тыеп каларга теләп: «Әти-әниең, туганнарың турында уйла. Терсәк якын булса да, тешләп булмаячак. Синең аска томырылуыңнан аларга җиңелрәк булыр дип уйлыйсыңмы әллә?» – дип ялвардым. «Әйе, – дип



җавап кайтарды ул. – Минем аркамда алар болай да күп хәсрәт кичерде. Алар, ниһаять, бәхетле булырлар», – дип, ике дә уйлап тормый, аска ташланды...

Үзем таштан булсам да, сез әллә минем йөрәгем дә таш дип беләсезме? Күпме түзәргә була мондый хәлләргә?! Нишләп сез – кешеләр – бер-берегезгә битараф? Нигә сез тормыш авырлыкларыннан чыгуның бүтән юлларын эзләмисез? Нигә мизгел генә булган яшәүнең кадерен белмисез?! Нишләп тирә-ягыгыздагы матурлыкны күрмисез?!.

...Аска ташланырга дип, инде түбә читенә килеп җиткән кыз бер адым артка чигенде. Коңгырт-кара күзләрен билгесезлеккә төбәп торды да, моңсу гына: «Ул егет минем абыем иде», – диде...

Кыз җирне сайлады...

...Мин түбәдән төшкәндә, шәһәргә кич аяк баскан иде. Шәһәрдә энгер-меңгер. Ә күңелдә – шом. Минем эчемә кереп оялаган шул шомны агачлар арасыннан иренеп кенә күз кыскан шәфәкъ нурлары да, кичке җылы җил дә куып тарата алмады. Күңел тынычлыгы җир белән күк арасында, кайдадыр билгесезлектә эленеп калган иде...

Ял сәгате

**Алинә Садыйкова, Зилә Фәсхиева** бергәләп төзеде.




! Алдагы санда чыккан кроссвордның дөрес җавапларын иң беренче булып җибәргән Галия Төхфәтуллованы котлыйбыз. Бүләкне безнең редакциядән килеп алырга мөмкин. Сездән сканвордка җаваплар көтеп калабыз!

Спорт

# Оттырганнан соң, җиңү кадерлерәк!

**Рифат СӘЛАХ**

Валерий Белов баш тренер булганнан бирле «Ак Барс» бер-бер артлы җиңү яулый.

Шунысы кызык, Көнчыгыш конференциядә дә, Харламов дивизионында да Казан командасының төп көндәше Түбән Кама «Нефтехимигы» булуы куанычлы. Әлегә «барслар» якташларыннан бер очкога калышып, «Көнчыгыш»та да, Континенталь хоккей лигасының гомуми таблицасында да өченче.

17 сентябрь көнне «Ак Барс» Иртыш ярларында Омскның «Авангард» командасы белән очрашты. Мәйдан хуҗалары узган матчта Түбән Кама «Нефтехимигы»на 2:6 белән оттырганнан соң, биш алка керттергән төп капкачылары Карри Рамоны бу уенда Эдуард Рейзвих белән алыштырды. Авангардның бу капкачысын да шундый ук язмыш көтәсен кем белгән! Казанлылар исә ике көн алдан «Югра»га (Ханты-Мансийск) 2:0 белән җиңелгәч, бу очрашуга тырнакларын ныклабрак кайрап килгән. Матч башында ук өстенлек кунаклар ягында иде.

Беренче периодның беренче яртысында ук хуҗалар ике тапкыр кагыйдә бозып өлгерде. Бер уенчыга өстенлектән файдаланып капитаныбыз Алексей Морозов 9 нчы минутта исәпне ачты. 16 нчы минутта Дмитрий Обуховның шәхси осталыгы барсларны 0:2 белән җиңеп баручы итте.

Икенче периодта һөҗүмчеләр күпме генә тырышмасын, һәр көрәштә капкачылар бирешмәде. Икенче серена ягыраганда беренче периодның исәбе шулай ук калды.



Өченче период башында ук сакчыбыз Илья Никулин исәпне казанлылар файдасына 0:3кә, 50 нче минутта икенче сакчыбыз Денис Куляш 0:4кә әйләндерде. Уен бетәргә унбиш секунд кала Алексей Морозов дубль ясап уенга нокта куйды.

Шулай итеп, «Ак Барс» Омскта җирле «Авангард»ны 0:5 исәбе белән тар-мар итте. Бүген «барслар» үз бозында Чиләбенең «Трактор» командасын кабул итә.

Кети-мети

- Доктор, безнең бабайга студент Вәлиев операция ясыймыни?
- Хәзер карыйбыз... Әйе, Вәлиев.
- Доктор, суеп атачак бит...
- Шулай дисезме? Ул чагында без аңа «икеле» чәпибез.

***

Вәли мәктәптән өенә кайтып кергәч:
- Җитте! Бүтән бу мәктәбегезгә ике аягымның берсен дә атламыйм!
- Нишләп?
- Укый белмим, яза белмим, ә сөйләшеп утырырга рөхсәт итмиләр.

***

Шәһәрдә институтта укыган улларына әтиәнисе күп итеп акча җибәрәләр дә язып куялар:
- Улым, акчаңны кысыбрак тот!
Күп тә үтми улларыннан хат килә:
- Әти, әни, кысып тот, дигәч, әллә катырак кыстым инде. Сез җибәргән акча үлде дә китте бит, тагын акча җибәрегез!

***

- Кичә Ләйсән Галимҗан Ибраһимовны укып торырга бирде.
- Ошадымы соң?
- Күңелсез... Текстта бер генә смайлик та юк...

DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Рифат Гали улы Сәлахов
Иҗат коллективы: Д.Р.Әхмәтова, А.Ю.Садыйкова, З.Ф.Фәсхиева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.

Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Карти» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Восстание ур., 60 й.